ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ
КОНСТИТУЦИОННЫЙ СУД РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯСЕ: ТАРИХЫ, ҮСЕШЕ, БҮГЕНГЕСЕ

# КОНСТИТУЦИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН: ИСТОРИЯ, РАЗВИТИЕ, СОВРЕМЕННОСТЬ

Казан — Казань
2017

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯСЕ

### Кереш. Гомуми мәгълүмат

Республиканың яңа дәүләтчелеге формалашуы процессында 1992 елда кабул ителгән Татарстан Конституциясе бик әһәмиятле роль уйный. Хәзерге Татарстан дәүләтчелегенең барлык яшәү дәверендә Татарстан Республикасында дүрт тапкыр текстлары, структуралары һәм тәкъдим ителгән принциплары белән өр-яңа конституцияләр кабул ителә. Яңа совет чоры Татарстан конституцияләрен кабул итү һәр очракта совет социалистик дәүләт үсешендә яңа этапны белдерә һәм Татарстанның күпмилләтле халкының мобилизациясе өчен мөһим фактор була.

1926 елгы беренче Конституция проекты барлыкка килүенең төп юридик чыганаклары итеп 1918 елгы Хезмәт иясе һәм эксплуатацияләнгән халыкның хокуклары турында декларацияне, 1918 елгы III Россия Республикасы федераль учреждениеләре турындагы Советларның бөтенроссия съезды резолюциясен, 1925 елгы РСФСР Конституциясен, 1921 елгы Татарстан Автономияле ССРның ҮБК һәм ХКС Татар телен гамәлгә кую турындагы декретын, 1924 елгы Татарстан ҮБК турында нигезләмәне карарга була.

Нәтиҗәдә 1926 елгы Татарстан ССР Конституциясенең проекты, шулай ук 1937 һәм 1978 елгы ТАССР Конституцияләре гамәлдәге Татарстан Конституциясен кабул итү өчен нигез булалар, республиканың норматив актларының гаять зур массивын барлыкка китерүгә хокукый база булып хезмәт итәләр.

1992 елгы Татарстан Республикасы Конституциясе яңа демократия институтларын

# КОНСТИТУЦИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

### Введение. Общая информация

Конституция Татарстана, принятая в 1992 году, сыграла важную роль в процессе становления новой государственности республики. За весь период современной татарстанской государственности в Республике Татарстан четырежды принимались совершенно новые по тексту, структуре и провозглашаемым принципам конституции. Принятие новых советских татарстанских конституций каждый раз знаменовало собой новый этап в развитии советского социалистического государства и являлось существенным фактором мобилизации многонационального народа Татарстана.

К главным юридическим источникам появления первого проекта Конституции 1926 года можно отнести Декларацию прав трудящегося и эксплуатируемого народа 1918 года, Резолюцию III Всероссийского съезда Советов о федеральных учреждениях Российской Республики 1918 года, Конституцию РСФСР 1925 года, Декрет ЦИК и СНК Автономной Татарской ССР о реализации татарского языка 1921 года, Положение о Татарском ЦИК 1924 года.

Проект Конституции Татарской ССР 1926 года, а также Конституции ТАССР 1937 и 1978 годов стали в итоге основой для принятия действующей Конституции Татарстана, послужили правовой базой для создания огромного массива нормативных актов республики.

Конституция Республики Татарстан 1992 года позволила сформировать новые институты демократии и собственные органы власти. Конституционное закрепление та-

һәм үз хакимият органнарын формалаштыру мөмкинлеге бирә. Президентлык, парламентлы вәкиллек органнары, конституциячел суд эшләрен башкару, җирле үзидарә кебек яңа институтларның Конституциядә беркетелүе Татарстанга сәяси һәм социаль-икътисади мөнәсәбәтләрне сыйфат ягыннан яңа дәрәҗәгә күтәрү бурычларын нәтиҗәле хәл итү мөмкинлеген ача.

ких новых институтов, как президентство, органы парламентского представительства, конституционное судопроизводство, местное самоуправление, позволило Татарстану эффективно решать задачи трансформации политических и социально-экономических отношений в качественно новое состояние.

## 1926 елгы Татарстан ССР Конституциясенең кабул ителү тарихы һәм структурасы




Татарстан ССР Конституциясе проекты 1926 елның 13 мартында VI Бөтентатар Советлар съездының пленар утырышында кабул ителгән. Конституция проекты 5 кисәктән, 7 бүлектән һәм 91 статьядан торган.

1926 елгы Конституция проекты нигезендә Татарстан ССР РСФСР составына федерация шартларында керә торган эшчеләр һәм крестьяннарның социалистик дәүләте дип игълан ителгән. 1926 елгы Конституция проектына күрә, Татарстан ССР чикләрендә бөтен хакимият эшче, крестьян һәм кызылармия депутатлары Советларыныкы булган.

Хезмәт республиканың бөтен гражданнарының бурычы дип танылган. Республика гражданнарына вөҗдан иреге, үз фикереңне белдерү иреге, җыелышлар иреге, берләшмәләр иреге бирелгән. Дәүләт барлык хезмәт ияләренә дә тулы, әтрафлы һәм түләүсез белем бирүне үз өстенә йөкләгән.

Конституция проекты Татарстан ССРның 12 кантоннан торган территориаль составын билгеләгән: Арча, Бөгелмә, Буа, Алабуга, Лаеш, Мамадыш, Минзәлә, Зөя, Спас, Тәтеш, Чаллы һәм Чистай.

Югары хакимият иясе итеп Татарстан ССРның Советлар Съезды игълан ителгән, съездлар арасында исә — Татарстан ССРның Үзәк Башкарма Комитеты.

1926 елгы Конституция проекты нәтиҗәдә РСФСРның БҮБК һәм РСФСРның Советлар Съезды тарафыннан расланмаган, Татарстан Автономияле ССРның эшчәнлеге исә 1922

## История принятия и структура проекта Конституции Татарской ССР 1926 года

Проект Конституции Татарской ССР был принят на пленарном заседании VI Всетатарского съезда Советов 13 марта 1926 года. Проект Конституции состоял из 5 разделов, 7 глав и 91 статьи.

Согласно проекту Конституции 1926 года Татарская ССР провозглашалась социалистическим государством рабочих и крестьян, входящим в состав РСФСР на условиях федерации. Вся власть в пределах Татарской ССР в соответствии с проектом Конституции 1926 года принадлежала Советам рабочих, крестьянских и красноармейских депутатов.

Труд признавался обязанностью всех граждан республики. Гражданам республики предоставлялась свобода совести, свобода выражения своих мнений, свобода собраний, свобода союзов. Государство обязывалось предоставить всем трудящимся полное, всестороннее и бесплатное образование.

Проект Конституции определял территориальный состав Татарской ССР как состоящую из 12 кантонов: Арский, Бугульминский, Буинский, Елабужский, Лаишевский, Мамадышский, Мензелинский, Свияжский, Спасский, Тетюшский, Челнинский и Чистопольский.

Носителем верховной власти провозглашался Съезд Советов Татарской ССР, а в период между съездами — Центральный Исполнительный Комитет Татарской ССР.

Проект Конституции 1926 года в итоге не

елгы СССР Конституциясе һәм 1925 елгы РСФСР Конституциясе, шулай ук Татарстан Автономияле ССРда кабул ителгән закон актлары нигезендә гамәлгә ашырылган.

### 1926 елгы Татарстан ССР Конституциясенең структурасы

**I кисәк.** Гомуми нигезләмәләр
*1 бүлек*
**II кисәк.** Совет хакимиятенең төзелеше турында
*2 бүлек.* Төп нигезләмәләр
*3 бүлек.* Үзәк хакимият турында
А. Татарстан Социалистик Совет Республикасы Советларының Съезды турында
Б. ТССРның Үзәк Башкарма Комитеты турында
В. Халык Комиссарлары Советы турында
Г. Халык Комиссариатлары турында
*4 бүлек.* Җирле хакимият турында
А. Советлар Съезды турында
Б. Башкарма комитетлар турында
В. Депутатлар советлары турында
Г. Җирле хакимият органнары вәкаләтләре чикләре турында
**III кисәк**
*5 бүлек.* Советларга сайлау турында
А. Актив һәм пассив сайлау хокукы турында
Б. Сайлауларны уздыру турында
В. Сайлауларны тикшерү һәм гамәлдән чыгару һәм депутатларны чакыртып алу турында
**IV кисәк**
*6 бүлек.* Бюджет хокукы турында
**V кисәк**
*7 бүлек.* Татарстан Социалистик Совет Республикасының гербы һәм флагы турында

был утвержден ВЦИК РСФСР и Съездом Советов РСФСР, а деятельность Автономной Татарской ССР осуществлялась в соответствии с Конституцией СССР 1922 г. и Конституцией РСФСР 1925 г., а также законодательными актами, принятыми в Автономной Татарской ССР.

### Структура Конституции Татарской ССР 1926 года

**Раздел I.** Общие положения
*Глава 1*
**Раздел II.** Об устройстве Советской власти
*Глава 2.* Основные положения
*Глава 3.* О центральной власти
А. О Съезде Советов Татарской Социалистической Советской Республики
Б. О Центральном Исполнительном Комитете ТССР
В. О Совете Народных Комиссаров
Г. О Народных Комиссариатах
*Глава 4.* О местной власти
А. О Съездах Советов
Б. Об исполнительных комитетах
В. О советах депутатов
Г. О пределах ведения местных органов власти
**Раздел III**
*Глава 5.* О выборах в Советы
А. Об активном и пассивном избирательном праве
Б. О производстве выборов
В. О проверке и отмене выборов и отзыве депутатов
**Раздел IV**
*Глава 6.* О бюджетном праве
**Раздел V**
*Глава 7.* О гербе и флаге Татарской Социалистической Советской Республики

## 1937 елгы Татарстан АССР Конституциясенең кабул ителү тарихы һәм структурасы




1937 елгы Татарстан АССР Конституциясе совет чорында республиканың беренче рәсми рәвештә үз көченә кергән Конституциясе булган. Ул ТАССР Советларының Гадәттән тыш съезды тарафыннан 1937 елның 25 июнендә кабул ителгән һәм РСФСР Югары Советының III сессиясе тарафыннан 1940 елның 2 июнендә расланган. Конституция татар дәүләтчелеге формалашуда иң әһәмиятле чорны тәмамлый һәм республика законнарының үсеш нәтиҗәсен үзендә гәүдәләндерә.

1937 елгы Татарстан АССР Конституциясе 11 бүлектән һәм 114 статьядан гыйбарәт булган. Республика Конституция нигезендә Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы — эшчеләрнең һәм крестьяннарның социалистик дәүләте дип игълан ителгән. Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы РСФСР составына автономияле республика хокукында кергән булган. Конституция Татарстан АССРда бөтен хакимият хезмәт ияләре депутатларының Советлары йөзендә шәһәр һәм авыл хезмәт ияләре кулында икәнлеген билгеләгән.

1937 елгы Татарстан АССР Конституциясе республиканың административ-территориаль бүленешен билгеләгән: аның составына 63 район һәм ике республика әһәмиятендәге шәһәр — Зеленодольск һәм Казан кергән. Автономияле республикаларның чикләрен һәм районнарга бүленешен билгеләү РСФСР карамагында булган, ләкин Татарстан АССР территориясе аның ризалыгыннан башка үзгәртелә алмаган.

## История принятия и структура Конституции Татарской АССР 1937 года

Конституция Татарской АССР 1937 года являлась первой, официально вступившей в силу Конституцией республики советского периода. Она была принята XI Чрезвычайным съездом Советов ТАССР 25 июня 1937 года и утверждена III сессией Верховного Совета РСФСР 2 июня 1940 года. Конституция завершила важнейший период в становлении татарстанской государственности и воплотила в себе итоги развития республиканского законодательства.

Конституция Татарской АССР 1937 года состояла из 11 глав и 114 статей. Согласно Конституции республика провозглашалась Татарской Автономной Советской Социалистической Республикой — социалистическим государством рабочих и крестьян. Татарская Автономная Советская Социалистическая Республика входила в состав РСФСР на правах автономной республики. Конституция устанавливала, что вся власть в Татарской АССР принадлежит трудящимся города и деревни в лице Советов депутатов трудящихся.

Конституция Татарской АССР 1937 года закрепляла административно-территориальное деление республики: в ее состав входили 63 района и два города республиканского подчинения — Зеленодольск и Казань. Утверждение границ и районного деления автономных республик относилось к ведению РСФСР, однако территория Татарской АССР не могла изменяться без ее согласия.

Конституция Татарской АССР 1937 года

1937 елгы Татарстан АССР Конституциясе хезмәткә, ял итүгә, картлыкта матди ярдәмгә, белем алуга хокук, хатын-кызга исә ирләр белән тигез хокуклар биргән. Дин дәүләттән һәм мәгарифтән аерылган. Ватанны саклау Татарстан АССРның һәрбер гражданының изге бурычы булган. Конституция гражданнарга сүз ирегең, матбугат ирегең, җыелышлар һәм митинглар ирегең, урамнарда йөрешләр һәм демонстрацияләр ясау ирегең гарантияләгән. 1937 елгы Татарстан АССР Конституциясенә күрә, Татарстан АССР Верховный Советы тарафыннан кабул ителгән законнар Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы рәисе һәм секретаре имзалары белән татар һәм рус телләрендә бастырылган.

ТАССРның дәүләт хакимиятенең югары органы булып Татарстан АССР Верховный Советы булган.

### 1937 елгы Татарстан АССР Конституциясенең структурасы

**I бүлек.** Җәмгыять төзелеше

**II бүлек**. Дәүләт төзелеше

**III бүлек.** Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасының дәүләт властеның югары органнары

**IV бүлек.** Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасының дәүләт идарәсе органнары

**V бүлек.** Дәүләт властеның җирле органнары

**VI бүлек.** Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасының бюджеты

**VII бүлек.** Суд һәм прокуратура

**VIII бүлек.** Гражданнарның төп хокуклары һәм бурычлары

**IX бүлек.** Сайлау системасы

**X бүлек.** Герб, флаг, башкала

**XI бүлек.** Конституцияне үзгәртү тәртибе

предоставляла право на труд, на отдых, на материальное обеспечение в старости, на образование, а женщине равные права с мужчиной. Религия отделялась от государства и образования. Защита отечества являлась священным долгом каждого гражданина Татарской АССР. Конституция гарантировала свободу слова, свободу печати, свободу собраний и митингов и свободу уличных шествий и демонстраций. Согласно Конституции Татарской АССР 1937 года законы, принятые Верховным Советом Татарской АССР, публиковались на татарском и русском языках за подписями председателя и секретаря Президиума Верховного Совета Татарской АССР.

Высшим органом государственной власти ТАССР являлся Верховный Совет ТАССР.

### Структура Конституции Татарской АССР 1937 года

**Глава I.** Общественное устройство

**Глава II.** Государственное устройство

**Глава III.** Высшие органы государственной власти Татарской Автономной Советской Социалистической Республики

**Глава IV.** Органы государственного управления Татарской Автономной Советской Социалистической Республики

**Глава V.** Местные органы государственной власти

**Глава VI.** Бюджет Татарской Автономной Советской Социалистической Республики

**Глава VII.** Суд и прокуратура

**Глава VIII.** Основные права и обязанности граждан

**Глава IX.** Избирательная система

**Глава X.** Герб, флаг, столица

**Глава XI.** Порядок изменения Конституции

## 1978 елгы Татарстан АССР Конституциясенең кабул ителү тарихы һәм структурасы

1978 елның 31 маенда ТАССР Верховный Советының чираттан тыш тугызынчы сессиясендә кабул ителгән ТАССР Конституциясе совет чорында кабул ителгән соңгы Конституция булган. 1978 елгы Конституциягә күрә, ТАССР — эшчеләр, крестьяннар һәм интеллигенциянең, республикадагы барлык милләт хезмәт ияләренең ихтыярын һәм интересларын чагылдырган гомумхалык социалистик дәүләте.

1978 елгы Конституция 10 кисәктән, 16 бүлектән һәм 161 статьядан торган.

Беренче тапкыр Конституциягә преамбула кертелгән, аның нигезендә Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы халкы, фәнни коммунизм идеяләрен кулланып, үзен бөтен совет халкының аерылгысыз өлеше дип аңлап, ССР Союзы Конституциясенә һәм РСФСР Конституциясенә туры китереп, әлеге Конституцияне кабул иткән һәм игълан иткән.

Конституция нигезендә ТАССРда бөтен хакимият халык кулында. Халык дәүләт хакимиятен Татарстан АССРның сәяси нигезен тәшкил иткән халык депутатлары Советлары аркылы тормышка ашырган. Дәүләтнең башка барлык органнары халык депутатлары Советлары контролендә булган һәм аларга хисап биргән. Беренче тапкыр ТАССР гражданнарының торакка хокуклы булулары теркәлгән. СССРда билгеләнгән бердәм союз гражданлыгы нигезендә ТАССРның һәр гражданы РСФСР һәм СССР гражданы булган.




## История принятия и структура Конституции Татарской АССР 1978 года

Конституция ТАССР от 31 мая 1978 года, принятая на внеочередной девятой сессии Верховного Совета ТАССР, была последней Конституцией, принятой в советский период. В соответствии с Конституцией 1978 года ТАССР — социалистическое общенародное государство, выражающее волю и интересы рабочих, крестьян и интеллигенции, трудящихся республики всех национальностей.

Конституция 1978 года состояла из 10 разделов, 16 глав и 161 статьи.

Впервые в Конституцию была введена преамбула, согласно которой народ Татарской Автономной Советской Социалистической Республики, руководствуясь идеями научного коммунизма, сознавая себя неотъемлемой частью всего советского народа, в соответствии с Конституцией Союза ССР и Конституцией РСФСР принимал и провозглашал данную Конституцию.

Согласно Конституции вся власть в ТАССР принадлежала народу. Народ осуществлял государственную власть через Советы народных депутатов, составляющие политическую основу ТАССР. Все другие государственные органы были подконтрольны и подотчетны Советам народных депутатов. Впервые было закреплено право граждан ТАССР на жилище. В соответствии с установленным в СССР единым союзным гражданством каждый гражданин ТАССР являлся гражданином РСФСР и СССР.

Впервые изменения, вносимые в Консти-

Беренче тапкыр Конституциягә кертеләсе үзгәртүләр ТАССР Верховный Советының ТАССР Верховный Советындагы барлык депутатларның өчтән ике өлешеннән ким булмаган күпчелеге тарафыннан кабул ителгән карары белән эшләнгән.

### 1978 елгы Татарстан АССР Конституциясенең структурасы

*(1978 елның 31 маендагы Татарстан АССР Законы редакциясендә)*

**I. Татарстан АССРның җәмгыять строе һәм политикасы нигезләре**

*1 бүлек.* Политик система

*2 бүлек.* Экономик система

*3 бүлек.* Социаль үсеш һәм культура

**II. Дәүләт һәм шәхес**

*4 бүлек.* Татарстан АССР гражданлыгы. Гражданнарның тигез хокуклыгы

*5 бүлек.* Татарстан АССР гражданнарының төп хокуклары, ирекләре һәм бурычлары

**III. Татарстан АССРның милли-дәүләт һәм административ-территориаль төзелеше**

*6 бүлек.* Татарстан АССР — РСФСР составындагы автономияле республика

*7 бүлек.* Татарстан АССРның административ-территориаль төзелеше

**IV. Татарстан АССРның халык депутатлары Советлары һәм аларны сайлау тәртибе**

*8 бүлек.* Халык депутатлары Советлары системасы һәм аларның эш принциплары

*9 бүлек.* Сайлау системасы

10 бүлек. Халык депутаты

**V. Татарстан АССР дәүләт власте һәм идарәсенең югары органнары**

*11 бүлек.* Татарстан АССР Верховный Советы

*12 бүлек.* Татарстан АССР Министрлар Советы

**VI. Татарстан АССРда дәүләт власте һәм идарәсенең җирле органнары**

туцию, производились решением Верховного Совета ТАССР, принятым большинством не менее двух третей от общего числа депутатов Верховного Совета ТАССР.

### Структура Конституции Татарской АССР 1978 года

*(в редакции Закона Татарской АССР от 31 мая 1978 г.)*

**I. Основы общественного строя и политики Татарской АССР**

*Глава 1.* Политическая система

*Глава 2.* Экономическая система

*Глава 3.* Социальное развитие и культура

**II. Государство и личность**

*Глава 4.* Гражданство Татарской АССР. Равноправие граждан

*Глава 5.* Основные права, свободы и обязанности граждан Татарской АССР

**III. Национально-государственное и административно-территориальное устройство Татарской АССР**

*Глава 6.* Татарская АССР — автономная республика в составе РСФСР

*Глава 7.* Административно-территориальное устройство Татарской АССР

**IV. Советы народных депутатов Татарской АССР и порядок их избрания**

*Глава 8.* Система и принципы деятельности Советов народных депутатов

*Глава 9.* Избирательная система

*Глава 10.* Народный депутат

**V. Высшие органы государственной власти и управления Татарской АССР**

*Глава 11.* Верховный Совет Татарской АССР

*Глава 12.* Совет Министров Татарской АССР

**VI. Местные органы государственной власти и управления в Татарской АССР**

*13 бүлек.* Халык депутатларының җирле Советлары

*14 бүлек.* Халык депутатларының җирле Советлары башкарма комитетлары

**VII. Татарстан АССРның экономик һәм социаль үсешенең дәүләт планы. Татарстан АССРның дәүләт бюджеты**

**VIII. Суд эшләре, арбитраж һәм прокурор надзоры**

*15 бүлек.* Суд һәм арбитраж

*16 бүлек.* Прокуратура

**IX. Татарстан АССРның гербы, флагы һәм башкаласы**

**X. Татарстан АССР Конституциясенең гамәлдә булуы һәм аны үзгәртү тәртибе**

*Глава 13.* Местные Советы народных депутатов

*Глава 14.* Исполнительные комитеты местных Советов народных депутатов

**VII. Государственный план экономического и социального развития Татарской АССР. Государственный бюджет Татарской АССР**

**VIII. Правосудие, арбитраж и прокурорский надзор**

*Глава 15.* Суд и арбитраж

*Глава 16.* Прокуратура

**IX. Герб, флаг и столица Татарской АССР**

**X. Действие Конституции Татарской АССР и порядок ее изменения**

## 1992 елгы Татарстан Республикасы Конституциясенең кабул ителү тарихы һәм структурасы




Гамәлдәге Конституция 1992 елның 6 ноябрендә Татарстан Республикасы Югары Советының XII сессиясендә кабул ителә. Аны кабул итү алдыннан Россия Федерациясе белән мөнәсәбәтләрдә республиканың статусы мәсьәләсенә карата 1992 елның 21 мартында референдум уздырыла. Референдумның нәтиҗәләре 1990 елның 30 августындагы Дәүләт суверенитеты турында Декларация белән беррәттән Татарстанның яңа Конституциясен төзүнең нигезен тәшкил итәләр.

1992 елның маенда Татарстан Республикасы Югары Советының X сессиясендә Татарстан Республикасы Конституциясе проектының беренче укылышы уза. Югары Советның даими комиссияләренә Конституциянең өч проекты карауга тәкъдим ителә. Беренче проект Татарстан Президенты М.Ш. Шәймиев тарафыннан тапшырыла, икенче проект — «Движение демократических реформ» төркеме тарафыннан, өченче проект «Народовластие» депутатлар төркеме тарафыннан тапшырыла. Президент тарафыннан тапшырылган Конституция проекты гомумхалык тикшерүен үтә, һәм төзәтмәләр шушы проектка гына килә. Конституция комиссиясе тарафыннан халык депутатларыннан килгән биш йөздән артык төзәтмә карала.

Татарстан Республикасы Конституциясе «Татарстан Республикасы Конституциясен гамәлгә кертү тәртибе турында» 1992 елның

## История принятия и развития Конституции Республики Татарстан 1992 года

Действующая Конституция была принята на XII сессии Верховного Совета Республики Татарстан 6 ноября 1992 года. Ее принятию предшествовало проведение 21 марта 1992 года референдума по вопросу статуса республики во взаимоотношениях с Российской Федерацией. Итоги референдума наряду с Декларацией о государственном суверенитете от 30 августа 1990 года легли в основу разработки новой Конституции Татарстана.

В мае 1992 года на X сессии Верховного Совета Республики Татарстан состоялось первое чтение проекта Конституции Республики Татарстан. На рассмотрение постоянным комиссиям Верховного Совета было предложено три проекта Конституции. Первый проект был представлен Президентом Татарстана М.Ш. Шаймиевым, второй проект был представлен группой «Движение демократических реформ», третий проект — от группы депутатов «Народовластие». Проект Конституции, который был представлен Президентом, прошел общенародное обсуждение, и предложения о поправках поступали только на этот проект. Конституционной комиссией были рассмотрены более пятисот поправок, поступивших от народных депутатов.

Конституция Республики Татарстан была введена в действие Законом Республики Татарстан от 30 ноября 1992 г. № 1665-XII «О порядке введения в действие Конституции Республики Татарстан». Текст Кон-

30 ноябрендәге 1665–XII номерлы Татарстан Республикасы Законы белән гамәлгә кертелә. Конституциянең тексты «Советская Татария» газетасының 1992 елның 12 декабрендәге 246—247 саннарында бастырылып чыга. «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» 2002 елның 19 апрелендәге 1380 номерлы Татарстан Республикасы Законы белән Татарстан Республикасы Конституциясе яңа редакциядә бирелә.

Барлыгы 2017 елның 1 октябренә кадәр Конституция текстына 17 тапкыр төзәтмәләр кертелә. Конституциягә беренче төзәтмә «Дәүләт хакимиятенең вәкиллекле һәм башкарма органнарын реформалауга бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» 1994 елның 29 ноябрендәге 2243–XII номерлы Татарстан Республикасы Законы белән кабул ителә. Соңгы төзәтмә «"Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль законга һәм "Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында" Федераль законны гамәлгә ашыру турында» 2012 елның 22 июнендәге 40–ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән кабул ителә.

### 1992 елгы Татарстан Республикасы Конституциясенең структурасы

*(2012 елның 22 июнендәге 40—ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

Татарстан Республикасы Конституциясе преамбуладан, 7 кисәктән, 4 бүлектән һәм

ституции был опубликован в газете «Советская Татария» от 12 декабря 1992 года № 246—247. Законом Республики Татарстан от 19 апреля 2002 года № 1380 «О внесении изменений и дополнений в Конституцию Республики Татарстан» Конституция Республики Татарстан была изложена в новой редакции.

Всего, по состоянию на 1 октября 2017 года, поправки в текст Конституции вносились 17 раз. Первая поправка в Конституцию была принята Законом Республики Татарстан от 29 ноября 1994 года № 2243–XII «О внесении изменений и дополнений в Конституцию Республики Татарстан в связи с реформированием представительных и исполнительных органов государственной власти». Последняя поправка была принята Законом Республики Татарстан от 22 июня 2012 года № 40–ЗРТ «О реализации Федерального закона "О внесении изменений в Федеральный закон "Об общих принципах организации законодательных (представительных) и исполнительных органов государственной власти субъектов Российской Федерации" и Федеральный закон "Об основных гарантиях избирательных прав и права на участие в референдуме граждан Российской Федерации"».

### Структура Конституции Республики Татарстан 1992 года

*(в ред. Закона Республики Татарстан от 22 июня 2012 года № 40—ЗРТ)*

Конституция Республики Татарстан состоит из преамбулы, 7 разделов, 4 глав и 126 статей. Деление на главы осуществлено исключительно в IV разделе.

126 статьядан гыйбарәт. Бүлекләргә фәкать IV кисәк кенә бүленгән.

**Преамбула**
**I кисәк.** Конституциячел корылыш нигезләре
**II кисәк.** Кеше һәм гражданның төп хокуклары, ирекләре һәм бурычлары
**III кисәк.** Административ-территориаль корылыш
**IV кисәк.** Дәүләт хакимиятен оештыру
*1 бүлек.* Татарстан Республикасы Дәүләт Советы
*2 бүлек.* Татарстан Республикасы Президенты
3 бүлек. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты
*4 бүлек.* Суд хакимияте. Прокуратура
**V кисәк.** Җирле үзидарә
**VI кисәк.** Татарстан Республикасының дәүләт символлары һәм башкаласы
**VII кисәк.** Татарстан Республикасы Конституциясен кабул итү һәм Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү тәртибе

**Преамбулада** Конституция нигезләнгән төп принциплар теркәлгән. Конституциянең преамбуласы кыска, аның нигезләмәләре Конституцияне тулаем һәм аның аерым бүлекләрен һәм статьяларын аңлауда, аның нормаларын дөрес итеп аңлатуда һәм куллануда үтә мөһим роль уйный.

Преамбулада белдерелгәнчә, Конституция, Татарстан Республикасының күпмилләтле халкы һәм татар халкы ихтыярын чагылдырып, кеше һәм граждан хокукларының һәм ирекләренең өстенлеген гамәлгә ашыра, халыкларның гомумтанылган үзбилгеләнү хокукына, аларның тигез хокуклылыгы, ихтыяр белдерүнең иреклелеге һәм бәйсезлеге прин-

**Преамбула**
**Раздел I.** Основы конституционного строя
**Раздел II.** Основные права,свободы и обязанности человека и гражданина
**Раздел III.** Административно-территориальное устройство
**Раздел IV.** Организация государственной власти
*Глава 1.* Государственный Совет Республики Татарстан
*Глава 2.* Президент Республики Татарстан
*Глава 3.* Кабинет Министров Республики Татарстан
*Глава 4.* Судебная власть. Прокуратура
**Раздел V.** Местное самоуправление
**Раздел VI.** Государственные символы и столица Республики Татарстан
**Раздел VII.** Порядок принятия Конституции Республики Татарстан и внесения изменений и дополнений в Конституцию Республики Татарстан

В **преамбуле** закрепляются основные принципы, на которых базируется Конституция. Преамбула Конституции лаконична, ее положения имеют исключительно важную роль в понимании смысла всей Конституции и ее отдельных глав и статей, в правильном толковании и применении ее норм.

Согласно преамбуле Конституция, выражая волю многонационального народа Республики Татарстан и татарского народа,реализует приоритет прав и свобод человека и гражданина, исходит из общепризнанного права народов на самоопределение, принципов их равноправия, добровольности и свободы волеизъявления, способствует сохранению и развитию исторических, национальных и духовных традиций, культур, языков, обеспечению гражданского мира и межнационального согласия, создает усло-

ципларына нигезләнә, тарихи, милли һәм рухи традицияләрнең, мәдәниятләрнең, телләрнең сакланып калуына һәм үсешенә, гражданнар татулыгын һәм милләтара килешүне тәэмин итүгә ярдәм итә, федерализм принципларында демократиянең ныгуы, Татарстан Республикасының социаль-икътисади үсеше, Россия Федерациясе халыкларының тарихи барлыкка килгән бердәмлеген саклап калу өчен шартлар тудыра.

Конституциянең **I кисәге** конституциячел корылыш нигезләренә багышланган. Конституциячел корылыш нигезләре Татарстанның дәүләт һәм җәмгыять корылышының төп үзенчәлекләрен билгелиләр: хакимиятнең бердәнбер чыганагы аның күпмилләтле халкы булган демократик хокукый дәүләт, Россия Федерациясенең субъекты. Татарстан Республикасында кеше, аның хокуклары һәм ирекләре — иң зур хәзинә. Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен тану, үтәү һәм яклау — Татарстан Республикасының бурычы.

